«РАСЛЫЙМ»

«Сәләт» ТРЯИФ
Генераль директоры

________ Ж.Ш. Сөләйманов

«___»____________2020 ел

«Әйдаманнар ярышы - 2020»
Республикакүләм әйдаманлык осталыгы конкурсы

НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**1. Ярышны оештыручылар**

**1.1.** «Әйдаманнар ярышы - 2020» Республикакүләм әйдаманлык осталыгы конкурсы (алга таба – Ярыш) Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы ярдәме белән Татарстан Республикасы «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды һәм «Сәләт» Яшьләр үзәге тарафыннан оештырыла.

**2. Гомум нигезләмәләр**

**2.1.** Ярыш Сәләтнең җәйге аланнарында катнашкан әйдаманнарның эшчәнлегенә нәтиҗә ясау буларак ел саен үткәрелә.

2.2. Түбәндәге мәгълүмат Оештыручылар тарафыннан билгеләнә һәм Әдип Әлмир тарафыннан раслана:

- ярышның нигезләмәсе;
- ярыш үткәрелү урыны һәм вакыты;
- ярышта катнашучылар исемлеге;
- казыйлар исемлеге;
- җиңүчеләрне бүләкләү фонды;
- ярышны үткәрү программасы.

**3. Ярышның максаты һәм бурычлары**

**3.1.** Ярыш үз алдына түбәндәге бурычларны куя һәм тормышка ашыра:

- әйдаманнарның профессиональ осталыгын арттыру өчен шартлар тудыру;

- балаларның ялын оештыруда инновацияләр, яңа технологияләр һәм юнәлешләр эзләү;

- әйдаманнарның нәтиҗәле эшчәнлек тәҗрибәсен үзара алмашу һәм тарату өчен шартлар тудыру;

- яшьләрнең иҗади һәм профессиональ мөмкинлекләрен тормышка ашыруда ярдәм итү.

## 4. Ярышны үткәрү тәртибе

**4.1.** Ярыш ике этапта үткәрелә:

- 1-нче этап – катнашучыларны читтән торып портфолиолар нигезендә сайлап алу (8-нче октябрь – 10-нчы ноябрь, 2020-нче ел);

- 2-нче этап – ярыш программасы (12-нче ноябрь – 15-нче ноябрь, 2020-нче ел)

**4.2.** Ярышта катнашырга теләк белдергән әйдаман 31-нче октябрьга кадәр selet.biz сайтында гариза тутырырга тиеш.

**4.3.** Читтән торып портфолиолар нигезендә сайлап алу этабы нәтиҗәсендә, катнашучылар 12-нче ноябрьдан 15-нче ноябрьга кадәр үткәрелүче ярыш программасында катнашырга чакырылалар.

**4.4.** Ярыш программасы нәтиҗәсендә җиңүче һәм лауреатлар билгеләнә.

**4.5.** Оештыру комитеты, көтелмәгән шартлар барлыкка килү очрагында, ярышның үткәрелү вакытын үзгәртергә хокуклы.

**4.6.** Оештыру комитеты гаризалар кабул итү вакытын озайтырга һәм Ярышны үткәрелмәгән дип игълан итәргә хокуклы.

## 5. Ярышның казыйлар шурасы

**5.1.** Ярышның казыйлар исемлеге Татарстан Республикасының танылган шәхесләре, «Сәләт» ТРЯИФ проектлары җитәкчеләре һәм җәйге аланнарда башҗитәк вазыйфасын башкарган, әлеге Ярышта үзләре катнашкан шәхесләрне кертеп оештыру комитеты тарафыннан төзелә һәм Әдип Әлмир тарафыннан раслана.

**5.2.** Казыйлар җиңүчеләрне Ярыш программасы нәтиҗәсендә билгели.

**5.3.** Казыйлар карары кире кайтып үзгәртелми һәм шикаятьләр каралмый.

## 6. Ярышта катнашучылар

**6.1.** Ярышта Сәләтнең җәйге аланнарында, күчмә мәктәпләрендә сәлкеш һәм әйдаман ролендә актив катнашкан, югары уку йортларында яисә урта махсус белем бирү йортларында укучы 17 яше тулган сәләтчеләр катнаша. Сәләтнең җәйге профильле аланнарында башҗитәк вазыйфасын үтәгән сәләтчеләр Ярышта катнаша алмыйлар.

**6.2.** «Премьер-лига»

**6.2.1.** «Премьер-лига» кысаларында Республикакүләм «Әйдаманнар мәктәбе»н узган, ким дигәндә 3 мәртәбә Халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында, яисә Сәләтнең җәйге профильле аланында кимендә 1 мәртәбә әйдаман булганнар яки Халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында башҗитәк ролендә 3 тапкырдан артык катнашмаган сәләтчеләр катнаша.

**6.3.** «Беренче лига»

**6.3.1.** «Беренче лига» кысаларында Республикакүләм «Әйдаманнар мәктәбе»н узмаган, Халыкара яшьләр уку-укыту «Сәләт» форумында иң күбе 1-2 мәртәбә әйдаман булганнар катнаша.

**6.4.** Катнашучылар әлеге нигезләмәнең барлык шартларын үтәргә тиеш.

## 7. Ярыш программасы

**7.1.** «Мин – сәләтле әйдаман»

**7.1.1.** Әлеге конкурс катнашучының «Мин – сәләтле әйдаман» темасына юнәлтелгән чыгышыннан гыйбарәт. Чыгыш түбәндәге сорауларны чагылдырырга тиеш:

- катнашучы турында мәгълүмат (тулы исеме, яше, уку йорты һ.б.);
- Сәләт проектларында катнашу;
- төрле дәрәҗәдәге уңышлары;
- кызыксынулары;
- ярыш темасына кагылган башка мәгълүмат.

**7.1.2.** Катнашучы өчен мәҗбүри шартлар:

- 3 минуттан артмаган чыгыш;
- электрон форматта булган презентация (Power Point, Prezi һ.б.)

**7.1.3.** Регламент:

- һәр катнашучыга чыгыш өчен 3 минут вакыт бирелә. Казыйлардан өстәмә сораулар булмаячак.

**7.1.4.** Бәяләү критерийлары:

- 7.1.1. пунктында булган барлык сорауларга да җавап булу;
- оригинальлек (чыгышның оригиналь булуы, катнашучының импровицациягә булган сәләте);

- артистлык (катнашучының сәхнәдә үз-үзен тота белү сыйфаты, ораторлык осталыгы, казыйлар һәм тамашачылар белән элемтә булдыру)

- татар телен белү дәрәҗәсе.

**7.2.** «Шәмчекләр»

**7.2.1.** Һәрбер катнашучы шәмчек программасын әзерли. Сайлап алу туры өчен шәмчек темасын катнашучы мөстәкыйль рәвештә сайлый. Финал этабы өчен темаларны оештыру комитеты тәкъдим итәчәк.

**7.2.2.** Шәмчекләрне уздыру тәртибе:

- кереш өлеш: шәмчекнең максаты һәм бурычлары, аның темасы;

- төп өлеш: аралашу;

- нәтиҗә ясау өлеше: шәмчектә катнашучылар үзләре өчен нинди файдалы мәгълүмат алалар;

- тәмамлау өлеше: берләшү мизгеле.

**7.2.3.** Регламент:

**- I тур.** Һәрбер катнашучыга шәмчек темасын тәкъдим итәргә 6 минут вакыт бирелә. Вакыт бетү белән, катнашучының чыгышы тәмамлана. Оештыру комитетының уртак фикере буенча вакыт регламенты үзгәрергә мөмкин.

**- II тур.** 1-нче тур нәтиҗәләре буенча һәр лигадан 9 иң яхшы катнашучы үзләренең шәмчекләрен уздыралар. Шәмчек уздыру вакыты – 20 минут. Оештыру комитетының уртак фикере буенча вакыт регламенты һәм катнашучылар саны үзгәрергә мөмкин.

**7.2.4.** Бәяләү критерийлары:

- теманы сайлау, аны аңлата алу; теманың күләме һәм актуальлеге;

- авторлык күләме, креативлык, яңалык;

- шәмчекнең дөрес структурасы булуы;

- шәмчек вакытындагы атмосфера;

- алып бару осталыгы;

- татар телен белү дәрәҗәсе.

**7.3.** «Сәләтле 60 секунд»

**7.3.1.** Катнашучы үзенең кабатланмас сәләтен күрсәтергә тиеш. Чыгышлар өчен билгеле бер жанр юк.

**7.3.2.** Регламент:

- һәр катнашучыга чыгыш өчен 60 секунд вакыт бирелә.

**7.3.3.** Бәяләү критерийлары:

- регламентны бозмау;

- оригинальлек.

**7.4.** Беренче лига өчен “Төркем эчендә уен” конкурсы

**7.4.1.** Катнашучы төркем белән үткәреп була торган уен әзерләргә тиеш.

**7.4.2.** Регламент:

- катнашучыга уенны тәкъдим итәр өчен 3 минут вакыт бирелә. Вакыт бетү белән, катнашучының чыгышы тәмамлана. Оештыру комитетының уртак фикере буенча вакыт регламенты үзгәрергә мөмкин.

**7.4.3.** Бәяләү критерийлары:

- авторлык, креативлык;
- яңача тәкъдим итү;
- алан эшчәнлегендә кулланып булу мөкинлеге.

**7.5.** Премьер лига өчен "Педагогик очраклар" конкурсы

**7.5.1.** Конкурс барышында һәрбер катнашучы үзенең балалар, аларның әти-әниләре, башҗитәкләр белән эшли белү осталыгын һәм педагогик очраклардан дөрес чыгу юлын таба белү сәләтен күрсәтә.

**7.5.2.** Регламент:

- педагогик очракны чишү өчен һәрбер әйдаманга 5 минут вакыт бирелә.

**7.5.3.** Бәяләү критерийлары:

- педагогик очракларны дөрес чишү;
- бала, әти-әни һәм җитәкче белән дөрес аралашу төзи белү.

**7.6.** "Топ-спикер"

**7.6.1.** Ораторлык осталыгы конкурсы. Топ-спикер темасы чыгыш ясау көнендә әйтелә.

**7.6.2.** Регламент:

- чыгыш 1 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

**7.6.3.** Бәяләү критерийлар:

- авторлык, креативлык;
- тыңлаучыларда эмоцияләр тудыру, ораторлык осталыгы;
- вакыт регламентын үтәү;
- татар телен белү дәрәҗәсе.
- теманың эчтәлеген ачу.

**7.7.** Ярышның финалына узган катнашучылар өчен программа финалны үткәрү көнендә хәбәр ителә.

**7.8.** Оештыру комитеты Ярыш программасына үзгәрешләр кертергә хокуклы.

## 8. Оештыручыларның контаклары:

**8.1.** Ярышның оештыру комитеты Сәләт йортында (Казан шәһәре, Островский урамы, 23-нче йорт) урнашкан. Элемтәләр өчен телефон: 8 (843) 292-16-00. Эш вакыты: 09:00-18:00, 8-нче бүлмә. Вконтакте челтәрендә рәсми төркем: https://vk.com/aidamanka